| СОВЕТ РОДНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОДНИКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2022 с. Родники № 24

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы турында**

Совет рәисе докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Родники авыл җирлеге Советы, гамәлдәге кануннарның үзгәрүенә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын раслау турында» карар проекты эшләнгәнен билгеләп үтә, ул җирлек Советы тарафыннан хупланды һәм халыкка җиткерелде, Җирлек халкы белән гавами тыңлауларда фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын узды.

Проект халык белән фикер алышу барышында кергән, гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләнгән.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 08.07.2004 ел № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 86-88 статьялары нигезендә,

**Родники авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставын кабул итәргә (Кушымта).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3.Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»урнаштыру юлы белән хокукый акт текстын халыкка җиткерергә.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 июнендәге 84 номерлы карары белән кабул ителгән,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы ;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2016 елның 4 мартындагы 25 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карары;
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 декабрендәге 39 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карары;
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 декабрендәге 59 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карары;
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендәге 120 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карары;

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

6. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

**Родники авыл**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **Е.А. Яковлева**